# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**09.12.2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 09 декабрендә 10:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Варклед-Бодья авылындагы Киров, Береговая урамнарына вак таш сатып алу һәм җәю.

2. Варклед-Бодья авылының Совет урамы буенча янгын гидранты урнаштыру.

4. Вәрклед-Бодья авылының Совет урамы буенча урнашкан суүткәргеч челтәрләргә хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау.

3. Вәрклед-Бодья авылы урамнарын кардан чистарту

4.МТЗ-82 тракторын карап тоту, аңа хезмәт күрсәтү һәм тагылма җиһазлар алу.

6. Варклед-Бодья авылы янгын машинасының штаттан тыш хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү.

7. Вәрклед-Бодья авылы зиратлары коймасын яңарту.

8. Чүп үләннәрен чабу һәм дизель ягулыгы сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 261 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 137 кеше, бу 52,7 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 137 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Варклед-Бодья авылындагы Киров, Береговая урамнарына вак таш сатып алу һәм җәю.

2. Варклед-Бодья авылының Совет урамы буенча янгын гидранты урнаштыру.

4. Вәрклед-Бодья авылының Совет урамы буенча урнашкан суүткәргеч челтәрләргә хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау.

3. Вәрклед-Бодья авылы урамнарын кардан чистарту

4.МТЗ-82 тракторын карап тоту, аңа хезмәт күрсәтү һәм тагылма җиһазлар алу.

6. Варклед-Бодья авылы янгын машинасының штаттан тыш хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү.

7. Вәрклед-Бодья авылы зираты коймасын яңарту.

8. Чүп үләннәрен чабу һәм дизель ягулыгы сатып алу.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Р.А.НУРМӨХӘММӘТОВ

Совет Кучуковского сельского поселения
Көчек авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002526
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ